/

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«23» 11 2021 ел Яр Чаллы № 4243

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 январендәге «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын раслау турында» 128 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 20 октябрендәге 2087-р номерлы күрсәтмәсе һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешү нигезендә,

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 январендәге «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын раслау турында» 128 номерлы карарына Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү хисабына 2021 елга Тукай муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә финанслау күләмен 427,8 мең сум күләмендә арттырып үзгәрешләр кертергә.
2. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасы паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганагы» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп финанслау күләме | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2021-2023 елларда 10 694 768,7 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2021 елда – 7 026 768,7 сум; |

| | |
|---|---|
| | 2022 елда – 1 834 000 сум;<br>2023 елда – 1 834 000 сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет акчалары һәм бюджеттан тыш чыганаклар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк. |

3. «2021-2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру чараларының II «Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар» бүлегенә «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура - сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә, блоклы модульле чаңгы базасын оператив идарә итү хокукында беркетелүгә бәйле рәвештә, Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итү һәм файдалануга тапшыру» пунктын кушымта нигезендә өстәргә.

4. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 23.11 1243 номерлы карарына кушымта

**«2021 - 2023 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» программасын гамәлгә ашыру буенча чаралар**

<table>
<tr><th rowspan="2">№</th><th rowspan="2">Чаралар исеме</th><th colspan="4">Финанс чараларын бүлү,<br>еллар буенча (сумнарда)</th><th>Финанслау чыганагы</th><th>Башкаручы</th></tr>
<tr><th>2021 ел</th><th>2022 ел</th><th>2023 ел</th><th>Барлыгы</th><th></th><th></th></tr>
<tr><td colspan="8">II. Профилактик чаралар һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча чаралар</td></tr>
<tr><td>1.</td><td rowspan="2">ТР муниципаль берәмлекләре территориясендә физик культура, массакүләм спорт үсеше өчен шартлар тәэмин итүгә, рәсми физкультура - сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыруга бәйле чараларны гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең муниципаль йөкләмәне үтәүне финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыру өлешендә, блоклы модульле чаңгы базасын оператив идарә итү хокукында беркетелүгә бәйле рәвештә, Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен социаль-мәдәни өлкә объектларын кабул итү һәм файдалануга тапшыру</td><td>427 800</td><td></td><td></td><td>275 650</td><td>Республика бюджеты</td><td rowspan="2">Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» МБУ</td></tr>
<tr><td>2.</td><td>4 278</td><td></td><td></td><td></td><td>Җирле бюджет</td></tr>
</table>